**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 12 мартыннан

№ 7-42

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Торак кодексы, «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлеедәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Төзелеш министрлыгының «Дәүләт торак күзәтчелеге һәм муниципаль торак контроле башкарганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычының типик индикаторларын раслау турында» 2025 елның 20 маендагы 301/пр номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Новошешминск муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Положениедә, Татарстан Республикасы Новошешминск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-107 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Новошешминск муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-136 номерлы, 2022 елның 8 апрелендәге 20-161 номерлы, 2023 елның 26 маендагы 34-272 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-310 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-379 номерлы, 2025 елның 17 апрелендәге 53-410 номерлы, 2025 елның 5 июнендәге 57-437 номерлы, 2025 елның 29 декабрендәге 5-33 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба - Положение) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 5, 6 пунктлар өстәргә:

«5. Муниципаль торакны контрольдә тотучы Контроль органында, Россия Федерациясе арбитраж суды тарафыннан энергия белән тәэмин итү (сату-алу, электр энергиясе (егәрлек), җылылык белән тәэмин итү һәм (яисә) кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү, су агызу, газ китерү (шул исәптән көнкүреш газын баллоннарда китерү) шартнамәләре (шартнамәләре)буенча бурычларны түләтү турында дәгъва

гаризасы (дәгъва гаризалары) кабул ителүе турында мәгълүмат булуы, күпфатирлы йортта милекчеләргә һәм кулланучыларга тиешле төрдәге коммуналь хезмәт күрсәтүне тәэмин итү һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тоту вакытында кулланылган коммуналь ресурсларны сатып алу максатында, каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләре күрсәтү килешүе (килешүләре) буенча, гомуми суммасы өч йөз мең сумнан артып киткән, карар кабул итү көненә кадәр унике ай эчендә барлыкка килгән бурыч турында мәгълүмат булуы.

6. Муниципаль торакны контрольдә тотучы Контроль органында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте вәкаләтле органы тарафыннан расланган куллану нормативыннан чыгып, өч исәп-хисап чоры рәттән җылылык өчен коммуналь хезмәткә түләү исәпләнүе турында мәгълүмат булуы.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы — Е.А. Тарнавский